Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.01.2026 Менделеевск ш. № 40

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге хезмәткәрләре балаларының туклануы өчен ата-аналар кертемнәрен түләүдән азат итү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 февралендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының 2022 елның 11 февралендәге ПР-27 номерлы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы йомгаклары буенча һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының 2022 елның 14 февралендәге 1КМ номерлы коллегиясе карарлары нигезендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге хезмәткәрләре гаиләләренә адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге хезмәткәрләре балаларының туклануы өчен 2026 елның 1 гыйнвареннан 2026 елның 31 декабрена кадәр ата-аналар кертемнәрен түләүдән азат итәргә .

2. Менделеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең балалары Менделеевск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә тукланган өчен җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталы"нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru
4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.М.Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Искаков